Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№29 (80)

26 сентябрь 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

Шушы көннәрдә ректор **И.ГАФУРОВ** **КФУ**ның **ЯР ЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫНА ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Ул бүлек һәм кафедра мөдирләре белән әңгәмә оештырды. Очрашуда Казан университетының «юл картасы»н булдыру мәсьәләләре каралды.

• • • •

**23 СЕНТЯБРЬ** көнне университетта **«ИНГЛИЗ ҺӘМ РУС ӘДӘБИЯТЫНДА ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕНДӘ МИЛЛИЛЕК ҺӘМ КОНФЕССИОНАЛЬЛЕК»** исемле халыкара конференция башланды. Чарада Төркия, Белорусия, Россиянең төрле югары уку йортларыннан килгән йөздән артык катнашучы доклад белән чыгыш ясады.

• • • •

Шул ук көнне Халыкара мөнәсәбәтләр институтында Hebrew Иерусалим университетының профессоры **МЕНАХЕМ ХОФНУНГНЫҢ АЧЫК ЛЕКЦИЯЛӘРЕ БАШЛАНЫП КИТТЕ**. Чыгышларында ул Израильнең күп гасырлар буена дәвам иткән территориаль халәте турында мәгълүмат бирде һәм хәзерге вакытта бара торган Израиль-Палестина конфликтының фактик сәбәпләрен атап үтте. Икенче көнне профессор тагын бер төркем тыңлаучылар өчен Израильнең Британия йогынтысына буйсыну тарихы турында лекция укыды.

• • • •

23 сентябрьдә **КФУ**ның «Н.И.Лобачевский ис. лицей» **МӘКТӘП-ИНТЕРНАТЫНА** «Лейпциг һөнәри белем бирү һәм квалификация күтәрү үзәге» ҖЧҖнең директоры **ФРАНК МЮЛЛЕР** һәм **ЛЕЙПЦИГ СӘҮДӘ** Сәнәгать палатасы хезмәткәре **НАТАЛИЯ КУТЦ ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Кунаклар белән очрашу барышында Н.И.Лобачевский ис. һәм IT-лицейның, КФУның башка структур бүлекчәләренең Германия гомуми белем бирү учреждениеләре белән хезмәттәшлек итү мәсьәләләре каралды. Нәтиҗәдә, үсеп килүче буында аңлы рәвештә профессия сайлауны тәрбияләү өчен, яңа эффектив методларны гамәлгә ашыру һәм укучыларның һөнәри ориентациясе буенча инде булдырылган тәҗрибәне уртаклашу максатыннан үзара хезмәттәшлеккә нигез салынды.

• • • •

**23 СЕНТЯБРЬ** көнне **КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ** һәм **КОЯМПУТТУР ТЕХНОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ** (Һиндстан) арасында үзара килешү турында **МЕМОРАНДУМ КАБУЛ ИТЕЛДЕ**. КФУ ректоры И.Гафуров һәм доктор С.Прасад хезмәттәшлек урнаштырырга кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Һиндстан университеты вәкилләре киләсе визитларында Физика институты һәм А.М.Бутлеров ис. химия институты лабораторияләре белән танышырга теләк белдерделәр.

• • • •

Шул ук көнне Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында **«ДИСЦИПЛИНААРА ПРОЕКТЛАРДА СОЦИОЛОГИК ТИКШЕРЕНҮЛӘР ТӘҖРИБӘСЕ»** түгәрәк өстәле булды. Чарада Лондоннан килгән кунаклар да катнашты.

• • • •

**24 СЕНТЯБРЬ** көнне ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Башта контроль йөкләмәләр үтәлеше һәм чаралар планы хакында Административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе А.Хашов җиткерде. Йөкләмәләрнең берсе университет телевидениесендә чит тел (инглиз һәм кытай) программаларын булдыру иде. Инглиз телендәге беренче чыгарылыш 26 сентябрьдә эфирга чыгачак. Алга таба PricewaterhouseCoopers (PwC) – КФУның компания-партнеры вәкиле Юрий Пуха чыгыш ясады. Ул уку йортының дөньякүләм әйдәп бара торган вузлар күрсәткечләренә якынаюга юнәлтелгән үсеш стратегиясе эшкәртмәсен тәкъдим итте. Ю.Пуха докладында КФУның хәзерге халәте турында сөйләде һәм аның стуктурасы, үлчәмнәре, студентлар саны белән охшаш булган башка университетлар белән чагыштырып күрсәтте. Аның фикеренчә, Казан университетының дөньякүләм рейтингларында өскә күтәрелеше 2018 елларга туры килергә мөмкин.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Влад Михневский фотолары

# «Талантлы әби»

Кирәк ул кешеләрне дәртләндереп җибәргән берәү. Гәрчә үзе арыганталган, ялыккан булса да – көч бирүче, сер бирмәүче! Юлның азагына-максатына җитәсе, эшне төгәлләп өлгерәсе – шунсыз тукталу юк. Бу вазифа үзенә дә көч бирә. Ә яңа көч-дәрт ял иттереп ала.

Ш.Галиев.

2нче биттә укыгыз.



• Юбиляр

# Шигърият гаме - яшәү мәгънәсе

(Әдәбият галиме Тәлгат Галиуллинга 75 яшь тулуга карата)



**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
профессор

Без, җир кешеләре, ике үлчәмдә яшибез: вакыт һәм урын киңлекләрендә. Әмма аларның безгә яшәү өчен бирелгән мөмкинлекләре икесенеке ике төрле: урын киң күңелле, әле яшисең һәм йөрерсең тибә икән, ул үзенең бер мөешендә көн күрергә мөмкинлеген тудырмый калмый. Ә менә вакыт бу яктан кырыс, ул гомерне чикләргә ярата.
Бик юмартланган очракта да кешенең яшәү дәверен йөз яшьтән дә арттырмаска тырыша. Халык акылын гәүдәләндергән Акмулла бабабыз юкка гына «якутлар табыладыр вакыт белән» димәгән. Шуңа күрә чын кеше үзенә яшәү өчен бирелгән вакытны мөмкин кадәр файдалырак, мәгънәлерәк итеп уздырырга омтыла икән, моңа гаҗәпләнергә туры килми.

Шушындыйрак фәлсәфи уйланулар күңелебезгә **Тәлгат Нәбиулла улы Галиуллин** шәхесе һәм эшчәнлеге хакында фикер йөрткәндә үзеннән-үзе килгән икән, моның асыл сәбәбе булырга тиештер. Бу чыннан да шулай.

Бездә каләмдәшләренең эшләрен, ул язучылар һәм шагыйрьләр булсынмы, ул әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр булсынмы, эзлекле рәвештә вакыт яктылыгында куеп караучы галимебез Тәлгат Галиуллиндыр, мөгаен. Аның китапларының исемнәренә генә игътибар итик: «Еллар юлга чакыра», «Безнең заман – үзе җыр», «Заман сулышы», «Гомер учагы», «Замана балалары»... Бу очракта «еллар», «заман», «гомер», «гасыр», «дәвам» сүзләренең вакытны белдерүче гыйбарәләр икәнлеге бәхәс тудырмый. Алар артында торган авторның вакытка төшенчә итеп кенә түгел, бәлки нииндидер бер тирән мәгънә салып караганлыгы ачык күренә. Әйе, иң дөрес һәм гадел хөкемдар – вакыт. Тәлгат Галиуллин вак иләкне эстетик бәяләүнең төп коралы итеп алган икән, бу аның төп үзәкне табуны тәэмин иткән акыл камиллеге турында сөйли.

1944 елда Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылгач, М.Мамин белән бергә педагогия институтында аспирантура үткән Хатип Госман һәм кайбер башка шәхесләрнең шунда эшли башладылар. Х.Госман татар шигърияте һәм нәзари, һәм гамәли яктан эзлекле өйрәнүдә үзенә бер мәктәп булдырды. Ш.Садретдинов, З.Мәҗитов кебекләр шул мәктәпнең талантлы шәкертләре булды. Аларга Нил Юзиев килеп кушылды һәм иҗаты белән бу өлкәдәге үсешне тагын бер баскычка күтәрде. Һәм ул эстафетаны Т.Галиуллинга тапшырды. Тәлгат Нәбиулла улы шул традицияләрне тиешле югарылыкта дәвам иттерүне үзенең намус эше итеп карады. Шул рәвешле, Казан университеты күп еллар буена шигърият фәненең үзәгендә торды (Казан педагогия институты исә прозаны үз итте). Шушы югарылыкның саклануын күрәсе килә, әмма бүген аны шулай колачлап дәвам иттерерлек көчләр бик күренми әле. Гасырлар һәрвакыт андый шәхесләрне тудырып тормый, күрәсең.

Әдәбиятыбызның урта гасырлар һәм унтугызынчы гасыр, егерменче йөз башы шигърияте, халык авыз иҗатының шигъри шәкелдәге мирасын яхшы белгән хәлдә, Т.Галиуллин, нигездә, совет чоры шагыйрьләре тудырган иҗатны өйрәнүгә күч салды.

Әдәбият галиме, гадәттә, тәнкыйтьче булудан үсеп чыга. Бу очракта без коллегабыз Т.Н.Галиуллинның фәннән тәнкыйтькә килүен күрәбез. Аның 1964 елда «Совет әдәбияты» журналының икенче санында басылган «Сибгат Хәким поэзиясенең халык авыз иҗаты белән бәйләнеше» дигән мәкаләсен фәнни хезмәт буларак таныырга кирәк. Ул, әлбәттә, 1970 елда якланачак диссертациянә әзерләүгә килүнең бер баскычы булып күзаллана. Аның «Яңа үрләр яулаганда» дигән беренче китабына (1972) кергән мәкаләләрне дә хәрәкәттәге эстетика дип карау белән генә чикләнеп булмыйдыр. Чөнки аларда бер үк вакытта шактый җитди фәнни карашлар да үткәрелә. Һәрхәлдә сүз тәнкыйтьнең югары кимәлдәге чагылышлары турында бара. Бу хезмәттәшебезнең фән үсешенең заман югарылыгында булырга омтылуы, тәнкыйтьче буларак эшчәнлегенә тиешле әзерлектә килүе белән аңлатыла. Шигърият мәйданында дистәләрчә шагыйрьләр иҗат итәләр, ә ул, әйтерсең лә, каяндыр бик яхшы күренә торган урыннан аларны колачлап, иңләп күзәтеп тора һәм шушы шигъри мохиткә гомуми дә, һәрбер каләм тибрәтүчегә хас аерым-аерым бәяләрен дә билгеләп тора.

Т.Галиуллин ничә дистә еллар буе һәр шагыйрьнең иҗатын күзәтеп, барлап, үсеш юлындагы уңышларына сөенеп, җитеп бетмәгән яклары җайлы гына күрсәтеп бара, шуның белән гомуми үсешкә үзенең сизелерлек өлешен кертеп тора. «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» (1985), «Дәвамлылык» (1987), «Шигърият баскычлары» (2002) һәм башка китаплары аның тәнкыйтьче һәм галим буларак үсә, камилләшә, фикерләренең тирәнәя баруын күрсәтә. Аның каләменең алга таба да шул югарылыкны саклап тирбәләчәгенә өмет нигезле.

• Белем баскычлары

24 сентябрь көнне УНИКСның Кече залында «Әйләнә-тирә мохит һәм тәбәкләрнең тотрыклы үсеше» дип аталган II Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясенең ачылу тантанасы узды. Бу чара Россиядә әйләнә-тирәне саклау елы һәм биосфераны өйрәнүгә нигез салучы галим В.И.Вернадскийга 150 ел тулу уңаеннан үткәрелә.

# Без табигать сагында!

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Ачылу тантанасында беренче булып сәламләү сүзе белән фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев чыгыш ясады. «Әлеге конференция бик кызык һәм мавыктыргыч булырга тиеш. Монда һәммәбезне дә борчыган әйләнә-тирәне саклау проблемаларына кагылган иң мөһим мәсьәләләр каралачак. Фикер алышу, тәҗрибә туплау – бу конференциянең төп бурычлары булып тора», – диде.

Бүгенге көндә тирә-ягыбыз бик күп үзгәрешләр кичерә. Әйтергә кирәк, алар уңай якка түгел. Кеше эшчәнлеге йогынтысында планетаның йөзе үзгәрә. Яшеллек кими, ә һава төрле завод-фабрикалардан чыккан төтен нәтиҗәсендә пычрана һәм бу, үз чиратында, кешедә төрле авырулар китереп чыгара. Табигатьне саклау максатыннан, республикабызда төрле проектлар, конференцияләр, акцияләр һәм бәйгеләр үткәрелә. Бу турыда тулырак ТР экология һәм табигый байлыклар министрлыгының мәгълүмати-аналитик эшчәнлек идарәсе мөдире В.Ч.Юранец сөйләде.

Очрашу барышында ТР Фәннәр академиясенең экология проблемалары институты директоры Р.Р.Шагидуллин да чыгыш ясады. Европаның иң олы тозсыз сулы Лодожское күлендә булган проблемалар турында Россия Фәннәр академиясе академигы В.А.Румянцев бәян итте. Чарада чит ил университетларыннан килгән кунаклар да шактый иде. Еврей университеты (Иерусалим) профессоры Тель-Ор Элиша «Су үсемлекләре ярдәмендә заманча технологияләр кулланып, калдыклар, туфрак һәм ләмнән авыр металларны чыгару» докладын тәкъдим итте. Пленар утырыш университетның Экология һәм география, Фундаменталь медицина һәм биология институтлары профессорлары, кафедра җитәкчеләре чыгышлары белән үрелеп барды.

Конференциянең максаты булып, бүгенге әйләнә-тирәбез торышына комплекслы анализ ясау, әйләнә-тирәнең төрле компонентларын тикшерүдә яңа методлар һәм заманча технологияләр куллану буенча тәҗрибә уртаклашу һәм алдагы ун елга экологияне саклау процессы үсешенә прогноз ясау тора. Конференциянең ябылу тантанасы бүген үтә. Оештыручылар кулгәан максатларга ирешкәндәр, дип ышанабыз. Табигатькә без йөз белән борылсак, ул да безне ярдәменнән ташламас.



Влад Михневский фотосы

• Шәхес

# «Талантлы әби»

Динара МИННЕКАЕВА



Влад Михневский фотосы

24 сентябрь көнне безнең университетның чыгарылыш студенты, кул эшләре остасы Флюра Калмурзинаның «Антресольләрдә» күргәзмә залында шәхси күргәзмәсе ачылды. Ул 20 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Бу шәхес турында ишеткәнем бар иде, ләкин артык аның белән кызыксынганым булмады. Ә юкка... мин бик күп әйбердән колак какканмын икән...

Күргәзмә залына кергәндә, анда энә чәнчер урын да юк иде. Флюра ханымның кул эшләнмәләре: мендәр тышлары, милли костюмнардан киенгән курчаклар, кошелек, телефон савытлары, матур итеп чигелгән түбәтәй, бияләй һәм башкалар... Диварларны күз явын алырлык картиналар бизи. Ә анда ни генә төшерелмәгән? Зәңгәр күл, авыл күренешләре, табигать гүзәллеге, атлар...

Ачылыш тантанасында Флюра апаның кызы, туганнары, дус-ишләре дә катнашты. Һәркайсы аның ни дәрәҗәдә талантлы булуы, бөтен эшне җиренә җиткереп башкаруы, максатчанлыгы турында каткат әйтте. Үзе исә, аны мактаганда чын татар хатын-кызларынча оялып кына: «Бу эш һәр кешенең кулыннан килә. Миндә талант юк, бары тик тырышлыгым аркасында гына шундый уңышларга ирешәм», – диде.

Ул бүген 85 яшькә җитә торган Ак әби. 1929 елда Башкортстанда туган Флюра апа Казан дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлый. Гомерен балаларга белем бирүгә багышлый, күп еллар мәктәпләрдә, урта һөнәри уку йортларында эстетика фәнен укыта. Лаеклы ялга чыккач, ныклап кул эшләре белән шөгыльләнә башлый. Махсус курсларда белемен арттыра. Бүгенге көндә күп күргәзмәләр оештырган, төрле конкурсларда җиңү яулаган кеше, бик четерекле, вак эшне нәзакәтле итеп башкара. Бисердан әйберләр ясау, алтын җепләр белән чигү зур сабырлык сорый.

Флюра апа башкаларга үз белгәнен җиткереп кенә калмый, күп матурлыкны күрергә дә өйрәтә. Дуслары аңа шуның өчен дә бик рәхмәтле. Кызы Асия дә бик матур итеп чигә.

Заманча әби яшьләр белән аралашырга, аларга үз киңәш-тәкъдимнәрен бирергә ярата. «Кызларның чалбар киеп йөрүләрен бөтенләй яратмыйм. Гүзәл затлар һәрвакыт үзләрен карарга, чибәр булырга тиеш. Татар халык киемнәре дөнья күләмендә безнең бренд була алыр иде. Татар хатын-кызлары беркайчан да яулыкка төренеп йөрмәгән. Безнең милли киемнәребез бик матур, шуларны кире кайтарырга иде», – ди. Ә кул эшләренә булган талантларын үстерергә теләүчеләргә, курыкмаска киңәш итә. «Тәҗрибә тырышлык белән килә», – ди ул.

Флюра әби бер минут та тик тормый. Ул һәрвакыт хәрәкәттә. Шушы көннәрдә генә дөнья күргән аның эшләре тупланган каталог яшь буенга үткәнгә кайтырга, бүгенгене аңларга һәм матур гореф-гадәтләребезне киләчәккә тапшырырга ярдәм итәр.

• Бездә кунак бар

# Глобальләшү шартларында хезмәттәшлек

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты



Влад Михневский фотосы

Шушы көннәрдә КФУда «Яңа буын» программасы кысаларында Казахстан һәм Кыргызстаннан килгән яшь галимнәр һәм төрле фәнни оешма вәкилләреннән торган делегация белән очрашу узды. Аларны уку йортыбызның актив студентлары һәм Казахстаннан килеп укучы студентлар каршы алды.

Кичә, ягъни 25 сентябрь көнне, КФУның ректорат утырышы залында укытучылар белән тагын бер кызыклы очрашу булды. Аны тышкы багланышлар буенча проректор **Линар Латыйпов** җитәкләде. Иң элек ул яшь галимнәргә кыскача гына КФУ, аның төп үсеш юнәлешләре хакында сөйләде. Аннары үзара җанлы әңгәмә башланып китте. Нигездә сүз глобальләшү һәм мультикультурализм мәсьәләләре турында барды.

Хәзерге заманда бер халык та изоляцияләнеп яши алмый. Шуңа да бүген еш кына глобальләшү хакында сүз йөртәбез. Әңгәмә барышында Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасындагы бәрелештә толерантлык җиңәргә тиеш дигән карашка карата да берничә фикер яңгырады. Бу уңайдан Л.Латыйпов алман идеалист-фәлсәфәчесе Шпенглер фикерен китерде. Ул үз вакытында XXI гасырда Европа Көнчыгышның көчле басымын сизәчәк, дип әйтеп калдырган. Проректор күзәтүенчә, бүген, чыннан да, әкренләп кенә бу процесс бара.

Билгеле булганча, мультикультурализм дигәндә, без һәр милләтнең үз милли гореф-гадәтләрен, үзенчәлекләрен саклап калуны күз алдында тотабыз. Бу да бик актуаль мәсьәлә булып кала бирә. Бигрәк тә күпмилләтле Россия шартларында.

Кыргызстанда Татар-башкорт милли-мәдәни үзәге эшләп килә икән. Шул үзәк ярдәмендә этник татарларның Россиянең төрле югары уку йортларында, шул исәптән, КФУда да белем алу мөмкинлеге бар. Әмма квоталар, ни кызганыч, чикле. Әңгәмә барышында аларны арттыру мөмкинлеге хакында да сүз булды.

Ахырда Казахстан кунаклары проректорга истәлек сувенирлары – тынычлык һәм хезмәт сөю символы – дөя сыны бүләк иттеләр. Очрашу үзара рәхмәт сүзләре һәм бергәләшеп фотога төшү белән тәмамланды.

• Белем баскычлары

22-28 сентябрь көннәрендә Кырым республикасының Судак шәһәрендә XXIII «Кеше һәм табигать. Социогадәти тарих мәсьәләләре» халыкара фәнни конференция уза.

# Кырымда безнең галимнәр

Чараның төп җаваплы оештыручысы булып, күренекле Россия галиме, «Тарих һәм хәзерге заман» журналының баш мөхәррире, философия фәннәре докторы, Казан император университетын тәмамлаган беренче профессиональ татар тарихчысының оныгы, «Татарлар тарихы» дигән фәнни хезмәт авторы **Эдуард Салман улы Кульпин-Гобәйдуллин** тора.

Традицион рәвештә, конференция халыкара, Россия-поляк статусына ия һәм Россия (Мәскәү, Звенигород, Анапа, Сочи) һәм Польша (Познань, Краков һәм Варшава) шәһәрләрендә уздырыла. Пленар утырыш һәм түгәрәк өстәл кысаларында 40тан артык доклад тыңланачак.

Чарада КФУның Халыкара багланышлар институтының тарих бүлеге профессоры **Альберт Борханов** та катнаша. Ул анда 3 доклад белән чыгыш ясаячак. Шуның икесе «Тарих һәм хәзерге заман» журналының чираттагы санында һәм Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты тарафыннан чыгарылган «Кеше һәм табигать. Социогадәти тарих мәсьәләләре» дип аталган җыентыкта басылып чыкты.

• Уңыш сере

# «Иҗади ташкында кайныйсым килә!»

Әңгәмәдәш **Алинә САДЫЙКОВА**

Университетыбыз үзенең яшь галимнәре белән горурлана ала. Алар, чын күңелдән фәнгә бирелеп, төрле ачышлар ясый, кешеләрнең тормышын яхшы якка үзгәртергә тырыша. Фундаменталь медицина һәм биология институтының биохимия кафедрасы ассистенты, укыту-методик эшләр буенча икенче категорияле белгеч, биология фәннәре кандидаты Диана Таҗетдинова да шул өлкәдә хезмәт куя. Уннан артык мактаулы диплом иясе булган Диананың алып барган эшчәнлеген белгән кеше аңа сокланмый булдыра алмый!



**– Казан университетында кайчаннан бирле эшлисез?**

- Студент елларын да исәпкә алсак, минем 13 ел гомерем университет белән бәйле. 2005 елда, КДУның биология-туфракны өйрәнү факультетының биохимия кафедрасын тәмамлагач, шунда ук гыйлем эстәргә аспирантурага кердем. Берничә елдан соң, «Микробиология һәм биохимия» белгечлеге буенча диссертация якладым. Башта лаборант-тикшерүче булып, аннары кече фәнни хезмәткәр, Технология трансферлары үзәгенең биологик юнәлеш консультанты вазифаларын башкардым. 2009 елдан биохимия кафедрасы ассистенты булып эшлим. Ул гына да түгел, 2010-2012 елларда әлеге факультетның чит ил студентлары белән эшләү буенча декан урынбасары. Факультетыбыз Фундаменталь медицина һәм биология институты булгач та, шушы вазифаны башкарам.

**- Сезне бу профессиягә сайларга һәм гомерегезне фән белән бәйләргә нәрсә этәрде?**

- Мәктәптә укыганда, мин экология фәне буенча олимпиадаларда катнаштым һәм өч ел рәттән лауреат булдым. Ул олимпиаданың бер этабы булган тикшеренү проектын Е.А.Арбузов исемендәге органик һәм физик химия институтында эшләү бәхетенә ирештем һәм шул вакытларда инде биология белән һөнәри рәвештә шөгыльләнәчәгемне аңладым.

**- Эшчәнлегегез турында укучыларга җентекләбрәк сөйләгез әле.**

- Минем эшчәнлек берничә тармактан гыйбарәт. Биохимия фәне буенча лаборатор һәм гамәли дәресләр алып барам, лекцияләр укыйм. Чит ил студентлары белән эшлим, аларга уку процессына бәйле мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итәм. Тышкы элемтәләр департаментының уку һәм укудан тыш бүлекләрен координацияләүче. Фәнни һәм инновацион проектларны җитәкләргә дә вакыт табам. Университет белән берлектә булдырылган, үсемлекчелек өчен биопрепаратлар эшләп чыгара торган ҖЧҖ «НПП АгроТехБио» кече инновацион компания директоры булып торам. Бу юнәлешне үстерү буенча без ике республика һәм өч федераль грант оттык. Боларга өстәп, кафедра хезмәткәрләрен коммерциальләштерү һәм интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә бәйле хокукларын яклау буенча консультациялим. Хәзерге вакытта, оештыру комитеты вәкиле буларак, 2013 елның 21-23 ноябрендә узачак «Биохимия – тормыш турындагы фәннәрнең нигезе» дип исемләнгән халыкара симпозиумга әзерләүдә катнашам. Чара биохимия кафедрасының 150 еллыгына багышланачак. Безнең кафедра Россиядә генә түгел, Европада да иң олылардан санала.

**- Сезнең фәнни ачышларыгыз да бардыр?**

-Хәзерге дөньяда принципиаль рәвештә әр-яңа ачыш ясавы кыен. Минем фәнни юнәлешем – биохимик характеристика һәм билгеләү методларын эшкәртү, «туфрак-үсемлек-кеше» системасының биоиминлеген саклау. Диссертацияне язганда, Татарстанның көньяк-көнчыгышының туфрагын тикшерергә туры килде. Нәтиҗәләр бик яхшы булмады: бу төбәк туфракларында төрле пычрата торган матдәләр булуы ачыкланды. Бу төбәкләр республиканың иң уңдырышлы җирләре булганлыктан, анда ел саен авыл хуҗалыгы культуралары үстерелә. Шуңа күрә анда экологик яктан зарарсыз ашамлык продукциясен җитештерү өчен, яңа стандартлар кертү кирәк. Бу юнәлештә безгә бөек галим, радиобиология, радиоэкология һәм агроэкология өлкәсендәге фәнне оештыручы, биология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты Роберт Гиниятуллович Ильязов бик зур ярдәм күрсәтте. Шулай ук биология фәннәре докторы, профессор, биохимия кафедрасы мөдире Фәридә Кашифовна Алимова җитәкчелегендә безнең коллектив үсемлекчелек өчен препаратлар ясап чыгарды. Бүгенге көндә үсемлекләрнең авыртуларын киметү өчен химик пестицидлар кулланалар. Әмма бу ысулның ике зур кимчелеге бар: беренчедән, пестицидлар әйләнә-тирәне пычраталар (рак авыртуы китереп чыгарырга мөмкин), икенчедән, үсемлек фитопатогеннары аларга ияләшә һәм үсемлек яңадан авырый башлый. Бу ситуация теплицаларда да, ачык туфракта да күзәтелә. Без эшләп чыгарган биопрепаратлар исә, микробка каршы пестицидларның санын киметә, кайбер очракларда аларны алыштыра да ала. Хәзер без бу препаратларны производствога кертеп җибәрү өстендә эшлибез.

**- Ничек уйлыйсыз, әлеге фән, әлеге юнәлеш университет һәм дөнья күләмендә тагын да алга китсен өчен нинди чаралар күрергә кирәк?**

- Бу сорауга Aix-Marseille University (Франция) университеты профессоры, рус телендә сөйләүче галимнәрнең халыкара ассоциациясе (RASA) президенты В.И.Сафаров сүзләре белән җавап бирәсе килә: «Фәнни үзәк һәм лабораторияләр үткәргән тикшерү эшләре университетта башкарылганнарга караганда күпкә эффектлырак һәм шактый югары дәрәҗәдә саналалар. Чөнки университет галимнәре һәм укытучыларының, фәнни эшчәнлектән кала, әле укыту нагрузкалары да бар. Ул нагрузкалар төрле илләрдә төрлечә. Мисал өчен, Португалиядә галим-укытучының нагрузкасы елына – 100 сәгать, Франциядә 192 сәгать, Россиядә – 600 сәгать (безнең университетта ким дигәндә 850 сәгать – *автор искәрмәсе*). Бу исә югары уку йортларында эшләүче Россия галимнәренең фәнни эшчәнлеккә һәм күнекмәләрне камилләштерергә вакытлары бик аз кала дигән сүз. Шуңа күрә, Россия университетлары АКШ вузларына тиңләшергә тели икән, укыту сәгатьләрен киметеп, хезмәткәрләрне фәнни ачышлар өчен азат итәргә кирәк».

**- Сезнеңчә Казан университетына медицина белеменең кире кайтуы әһәмияткә иями?**

- Медицина белеменең кире кайтуын бер яктан, үткәннәрнең кайтуы дип әйтергә була. Икенче яктан, бу медицина өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләрнең алга китүе өчен көчле импульс булып тора. Бөтендөнья тәҗрибәсе күрсәткәнчә, тикшеренү үзәкләре дәвалау оешмалары белән берлектә эшләүләре тагын да югары нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Авыруны кисәтү һәм дәвалауда яңа технологияләр (предикатив медицина), дисциплинаара өлкәсендә квалификацияле белгечләр әзерләү Россия медицинасының дәрәҗәсен арттырырга һәм гади пациентларны сәламәтрәк итәргә мөмкинлек бирәчәк. Институтыбызда биомедицина өлкәсе буенча тикшеренүләр монарчы да башкарылды. Шулай булгач, бу бары тик белем бирү процессының югары конкуренция шартларындагы логик эволюциясе.

**- Фән дөньясында шундый актив булгач, гади тормышта да бер урында гына тормыйсыздыр. Сезнең тормыш позициягез нинди?**

- Тырышкан морадына ирешер. Хыяллар чынга аша, әмма аның өчен бик тырышырга кирәк. Дөнья буенча сәяхәт итәсем һәм иҗади ташкында кайнап яшисем килә!

• Сәяхәттән кайткач

**Мин университетымны бик яратам. Мәһабәт бинаалары, хөрмәтле укытучылары, якын төркемдәшләрем белән кадерле ул миңа. Биредә тудырылган һәр мөмкинлектән файдаланырга тырышам. ДААД стипендиясе буенча, Алман иленең Мангейм шәһәрендә немец телен өйрәнү курсларында катнашуым киләчәктә зур этәргеч булыр.**

**Ләйсән ШӘЙМӨХӘММӘТОВА,**
Яр Чаллы институты студенты



■ *Сулдан беренче Ләйсән. Германиядәге дуслары белән.*

# Тәҗрибә юллар аша килә

**✦ Белешмә**

DAAD – Германия югары уку йортларының үзидарә оешмасы. Ул барлыгы 236 немец уку йортын һәм 124 студент оешмасын берләштерә. DAADның 14 илдә вәкиллеге һәм 51 мәгълүмат үзәге бар. Германиянең академик алмаш оешмасы елына 60 000 стипендия тапшыра.

Бер ай дәвамында барган курсларда 58 илдән 300ләп студент катнаштык. Оештыручылар әйткәнчә, быелгы курслар Мангейм университеты тарихында иң күп санлы студентлар кабул итүе белән истә калачак.

Курслар башланганчы, һәр студентның тел белү дәрәҗәсен тикшерделәр. Имтихан нәтиҗәләре буенча 21 төркемгә бүлендек. Мин 17 төркемдә укыдым. Һәр төркемгә икешәр укытучы билгеләнде. Дәресләр, гадәттә, иртәнге тугыздан уникегә кадәр дәвам итте. Аннары һәр теләгән кешегә төрле семинарларда катнашу мөмкинлеге бирелде. Анда семинарлар гел уен формасында үтә. Шуңа күрә бер-беребезгә дә бик тиз ияләштек. Башкалар алдында чыгыш ясаганда, каушау, оялу хисе бөтенләй юкка чыкты.

Курслар вакытында бик күп чаралар оештырылды: бергәләшеп немец телендә кинолар карадык, боулинг уйнап, төрле клубларда күңел ачтык. Шулай ук бик күп экскурсияләрдә булдык. Сыра ясау фабрикасы, вино җитештерә торган завод һәм виноград плантацияләрен дә күрдек. Франкфурт, Бад Дюркайм, Гейдельберг, Роттенбург, Вормс һәм тагын бик күп башка шәһәрләрне күрдек, андагы тормыш белән таныштык. Шуны әйтәсем килә: Германиядә төрле дин һәм милләт кешеләре янәшә торып, бер-берсен бик хөрмәт итеп, дус һәм тату яшиләр. Безгә, чит ил студентларына да, шуны күрсәтергә тырышып, төрле дини йолаларга нигезләнгән чаралар узды. Католиклар чиркәвендә, синагога һәм мәчеттә булдык. Беренче карашка аерылып торган диннәр арасында уртак билгеләрне табу бик тә кызык күренеш икән.

Читтән килгән барлык студентлар да махсус тулай торакта яшәделәр, һәрберебезгә аерым бер бүлмә бирелде. Университет ашханәсендә дә, төрле кафеларда да тукландык, үзебез дә ашарга пешердек.

Курслар тәмамлангач, белемнәрне тикшерү максатыннан, имтихан тапшырдык. Ул дүрт өлешкә бүленгән иде. Беренче өлештә – грамматик биремнәр, икенче өлештә – билгеле бер темага инша язу, өченчесе – текст буенча эш, аны аңлау һәм сорауларга язмача җавап бирү, дүртенчесе телдән әңгәмә алып бару, төрле сорауларга җавап бирүдән гыйбарәт иде.

Имтихан нәтиҗәләре һәм дәрестә катнашуга карап, һәрберебез махсус сертификат белән бүләкләндек. Алман илендә билгеләр безнекеннән бик аерыла. Анда алты балл буенча билгелиләр. Андагы «1» – безнеңчә «5»не аңлата, ә «6» иң түбән билгене аңлата.

Немец теле курслары, әлбәттә, бу тел буенча белемнәремне арттырды, бик күп студентлар белән танышу һәм дуслашу, чит илгә чыгу мөмкинлеге бирде. Алман иле халкының үзенчәлеген, аның тарихын һәм мәдәниятен яхшырак күзалларга ярдәм итте.

• Хыял иле

# Тормыш Метросы

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

**Алга киткән шәһәрләрнең һәммәсендә диярлек метро бар. Казанда метро ачылгач, күп пассажирлар автобус-троллейбуслардан гына түгел, хәтта шәхси машиналарыннан да шунда күчте. Ә метроның һәр кешедә бар икәнлеге турында беркемнең дә уйлап караганы булмагандыр әле.**

*Кеше туа һәм өч яшендә, үзенең беренче «Балалар бакчасы» станциясенә утырып, сәяхәт итә башлый. Әлеге станция яңа хис-кичерешләр, беренче һәм шул ук вакытта моңсу ачышлар белән тулы була. Бу станциядә син дөнья белән таныша гына башлыйсың. Кайвакыт метро кагыйдәләренә буйсынмыйча, бөтен вагонның астын-өскә китереп уйныйсың, тавышланасың, йөгерәсең...*

*Тормыш дәвам итә һәм синең алдыңда үз ишекләрен «Мәктәп» станциясе ачып җибәрә. Төрле уй-хыялларга биреләсең, киләчәккә планнар корасың, үзеңә ошаган юлдашыңа күз кысып та өлгерәсең. Бу юлда син тормыш метросының нәрсә икәнен аңлый башлыйсың. Алдагы юлда ни көткәнен белмәсәң дә, кулдан килгәннең барысын да югары дәрәҗәдә эшләргә омтыласың. Яңа җиңүләр, кайгы-шатлыклар, арып-талулар юл буена сине озата бара. Монда син киләчәк юлыңны, маршрутыңны дөрес итеп сайларга тырышасың. Алга таба син «Академическая» яисә «Университет» станцияләренә күчә аласың. Әйтергә кирәк: бу станцияләр аша үтмәгән кешегә киләчәктә үз юлын табу авыррак булачак.*

*Үз станцияңне сайлагач, син күп борылышлы яңа юлдан хәрәкәт итә башлыйсың. Әлеге юл бик күп сюрпризлар, көтелмәгән вакыйгалар, онытылмас мизгелләр белән үрелеп бара. Монда син яңа дуслар табасың яки «Мәктәп» станциясендә бергә барган иптәшләреңне очратасың. Кемдер башы белән «Китапханә» станциясенә кереп «чума», кемдер «Спорт» станциясендә көнен уздыра. Ә кайсыларыдыр «Хезмәт» станциясе вагонына күчеп, үзен укуга да, эшкә дә багышлый. Шулай итеп поезд үз юлын дәвам итә.*

*Хәзер син үзеңә-үзең хуҗа. Ләкин ялгышлар юлыңны газапка әйләндерергә мөмкин, шуңа күрә тукталышларның дөресен сайла! Әле синең станцияләрең бик күп булачак!*

• Аклы-каралы дөнья

# КФУда «китаплар өе» бар

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

**Күптән түгел студентлар арасында «сковородка» исемен йөрткән, университетның төп бинасы каршында урнашкан җирдә бер бөлөкәй генә агачтан ясалган «өй»гә игътибар иттем. Беренче чиратта, нәрсә икән бу, дигән сорау башыма килде. Шөкер, «өй»нең тышкы ягында – «Синең китапханәң» дип язылган һәм Интернет-төркемгә сылтама куелган иде. Нәкъ менә ул минем соравыма җавап табарга булышты да инде.**



Интернетчелтәрендә ***vk.com.knigodom_kzn.ru*** дигән сылтама аша узгач, мин китап сөючеләр иленә эләккәнемне аңладым. Ә менә университет янында урнашкан «өй» – ул «китаплар өе» икән. Ул буккроссинг агымының асылына нигезләнеп уйлап чыгарылган. Биредә һәр теләгән кеше китаплар калдыра ала. Шулай ук үзен кызыксындырган китапны укыр өчен алып китәргә дә рөхсәт ителә. Әмма бер мөһим шарт бар: китапны кире үз урынына китерергә кирәк. Шундый «өй» яшьләрдә белем чишмәсенә булган мәхәббәтне ныгытырга булыша һәм инде укылган, өйдә тузан җыеп яткан китапларга яңа тормыш бирә.

«Китаплар өе»н ясау идеясе инде ел ярым элек Казанның өлкән яшьтәге скаутларында барлыкка килә. Алар башкала өчен нинди дә булса файдалы әйбер эшләргә тели. Кыш көне «Кесәдәге шигырьләр» дигән акция уздыра. Аннары аларга якын дуслары чит илдә популяр булган буккроссинг агымы турында сөйли. Берникадәр уйланганнан соң, яшьләр Казанда да буккроссерлар санын арттыру максатын куя һәм аны тормышка ашыруга керешә. Нәтиҗәдә, сентябрь башында инде әйтеп кителгән «өй»не төзи һәм университет территориясендә урнаштыра.

Казан скауты Олег Шатин – әлеге проектны тормышка ашыруда актив катнашкан кеше. Ул эшенең нәтиҗәсен дә күрә башлаган. Чынлап та «өй»дән кунак өзелми. Әмма Олегны кайбер проблемалар да борчый икән: «Бөтен алынган китаплар да кире үз урынына кайтарылмый. Әлбәттә, бу һәр кешенең намусы белән бәйле. Китапларны куючылар санына караганда, аларны алучылар саны күпкә артык булуы бераз кәефне төшерә», – дип фикерләре белән уртаклашты.

Бүгенге көндә социаль челтәрдәге төркемдә 160лап кеше теркәлгән, бу сан артуын дәвам итә. Катнашучыларның актив аралашуы, фикерләр бүлешүе Казанда буккроссинг агымының чәчәк ату чоры башланганы турында сөйли.

Агымның тарихына күз салсак, буккроссингны Интернет-технологияләр белгече Рон Хорнбекер уйлап чыгара. Башта ул аның асылын аңлата торган язулар тыгылган китапларны үз отеленең холлында калдырып китә. Ярты елдан соң, буккроссерлар саны инде өч йөз кешедән арта. Казанда буккроссинг агымы әле берничә ел элек кенә барлыкка килә башлый. Бу вакыт аралыгында китапларны калдыру өчен, төрле куркыныч булмаган урыннар билгеләнә. Алар күбрәк кибетләрдә, отельләрдә урнаштырыла.

Университетыбыз территориясендә Казан скаутлары тырышлыгы белән ясалган «Китаплар өе» – башкалабыз өчен уникаль проект. Озакламый шундый «өй»ләр шәһәрнең төрле урыннарында урнашыр дип өметләнергә генә кала.

***P.S.** Мин үзем дә буккроссерлар рәтенә кердем. Кемдер калдырган китапны уку бик кызык икән. Әмма калдырылган китаплар арасында татар китаплары булмау берникадәр кәефне төшерде. Татар яшьләре дә бик яратып китап укый бит! Дуслар, әйдәгез буккроссерлар рәтенә кереп, татар әдәбиятын тагын да популярлаштырыйк!*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.